ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**БИЛГЕЛӘМӘСЕ**

**«2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.М. Равилов шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

Казан шәһәре 2017 елның 2 феврале

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Л.В. Кузьмина, Р.Г. Сәхиева, А.А. Хамматова, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданин Р.М. Равилов шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Р.М. Равилов «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган норматив нигезләмә белән социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренә 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәрге чор өчен телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләү күләме билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Р.М. Равилов — Казан шәһәрендәге күпфатирлы йорттагы торак урын милекчесе, әлеге йортта милекчеләрнең гомуми җыелышында 2016 елга күпфатирлы йортның уртак милеген карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән ТВ кабул итү гомумйорт челтәрен карап тоту өчен тарифларны раслау турында карар кабул ителгән. Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, ул кабель телевидениесенә тоташкан һәм күмәк антеннадан файдаланмый, ләкин дәгъвалана торган норма нигезендә аңа техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләргә мәҗбүр. Шуңа күрә ул, телевидениене күмәк кабул итү системаларына аларны куллану-кулланмауга карамастан техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләү билгели торган дәгъваланучы хокукый норма аның конституциячел хокукларын боза һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә, дип саный.

Үз позициясен дәлилләп, гражданин Р.М. Равилов шуны күрсәтә: федераль законнар нигезендә телетапшырулар элемтә хезмәтләренә карый һәм «Элемтә турында» 2003 елның 7 июлендәге 126-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы буенча әлеге хезмәтләрне элемтә хезмәтләрен кулланучылар (абонентлар) белән граждан законнары һәм элемтә хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләре нигезендә төзелә торган элемтә

хезмәтләрен күрсәтү турында шартнамә нигезендә элемтә операторлары күрсәтәләр. Телетапшырулар һәм (яки) радиотапшырулар өчен элемтә хезмәтләрен күрсәтү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 22 декабрендәге 785 номерлы карары белән расланган һәм элемтә хезмәтләрен күрсәтү турында шартнамәне төзегәндә һәм үтәгәндә элемтә хезмәтләрен кулланучылар белән элемтә операторларының үзара мөнәсәбәтләрен, шул исәптән элемтә операторларының һәм элемтә хезмәтләрен кулланучыларның хокукларын һәм бурычларын, күрсәтелгән элемтә хезмәтләре өчен исәп-хисап башкару формасын һәм тәртибен регламентлаштыралар.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак урынны карап тоту һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтелүгә түләү өчен түләү документына телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләүне кертү тәртибе мәсьәләләре турында» 2016 елның 13 июлендәге 21928-АЧ/04 номерлы хаты нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре үз ихтыярлары буенча телетапшырулар өчен элемтә хезмәтләрен күрсәтүдән баш тартырга һәм телевидениене күмәк кабул итү системасыннан файдаланмаска (элемтә операторы белән элемтә хезмәтләрен күрсәтү турында шартнамәне төземәскә яки аны өзәргә) хокуклы.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.М. Равилов Татарстан Республикасы Конституция судыннан «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланган телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләү күләмен билгеләү мәсьәләсе Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде, ул 2016 елның 7 июлендәге 69-П номерлы карарында шундый нәтиҗә ясый: Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы дәгъвалана торган карарының шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен тариф билгели торган хокукый нигезләмәсе күпфатирлы йорттагы милекне тиешле хәлдә тоту хокукый механизмының бер элементы булып тора һәм кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яки башкача боза торган итеп карала алмый һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына каршы килми.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шуны күрсәтте: дәгъвалана торган хокукый җайга салу торак урыннар милекчеләренә гомуми җыелышта уртак милек составын һәм аны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча, шулай ук андый милек составын аерым милек төрләрен, шул исәптән телевидениене күмәк кабул итү системаларын, аларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт ясау өчен түләүне туктатып, аннан чыгару юлы белән киметү буенча конкрет хокукларны гамәлгә ашырырга комачауламый, чөнки Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту кагыйдәләренең 1 пункты нигезендә урыннар милекчеләре уртак милек составын мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

Татарстан Республикасы Конституция суды шулай ук билгеләп үткәнчә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының әлеге карары түбәндәге шарт белән генә кулланылырга мөмкин: күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре аларның ихтыярына бәйле булган һәм бәйле булмаган теге яки бу сәбәпләр буенча үзләренә йөкләнгән күпфатирлы йорттагы уртак милекне карап тоту бурычын үтәргә юнәлдерелгән закон белән билгеләнгән гамәлләрне башкармаганнар, атап әйткәндә, гомуми җыелышта күпфатирлы йорт белән турыдан-туры идарә итү ысулын сайламаганнар һәм (яки) торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгәннәр.

Татарстан Республикасы Конституция судының китерелгән хокукый позициясе үз көчендә кала.

Мондый шартларда, гражданин Р.М. Равилов яшәгән күпфатирлы йортта торак урыннар милекчеләренең гомуми җыелышта күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлаганнарын һәм торак урынны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән ТВ кабул итү гомумйорт челтәрен карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул иткәннәрен исәпкә алып, дәгъвалана торган норма мөрәҗәгать итүченең конкрет эшендә кулланылмаган һәм кулланыла алмаган, шуңа күрә аның шикаяте «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы белән билгеләнгән бирелү мөмкинлеге критерийларына җавап бирми һәм шуның нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга кабул ителә алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72 статьяларына, 73 статьясындагы беренче өлешенә һәм 101 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «2016 елга Казан шәһәренең торак фондына караган торак бинадан файдаланган өчен (наем өчен түләү), торак биналарны карап тоткан өчен түләү күләме турында» 2015 елның 23 декабрендәге 4459 номерлы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымтаның 4 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.М. Равилов шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки билгеләнгән таләпләр нигезендә шикаять карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.М. Равиловка һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 3-О**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**